
Салават РӘХМӘТУЛЛА
Сандыктагы хәзинә
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
6+

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Р97

Рəссамы *Рөстəм Хəбибуллин*

**Рəхмəтулла, С. И.**

Р97 Сандыктагы хəзинə : балалар өчен шигырьлəр, поэмалар, табышмаклар, шарадалар / Салават Рəхмəтулла. – Казан : Татар. кит. нəшр., 2017 – 87 б. : рəс. б-н.
ISBN 978-5-298-03322-0

Башкортстанда яшəп иҗат итүче татар шагыйре Салават Рəхмəтулланың əлеге мавыктыргыч китабында кызыклы шигырьлəр, серле табышмаклар белəн танышырсыз. Тылсымлы сандыкта нинди хəзинə ятканын белəсегез килсə, рəхəтлəнеп бу җыентыкны укыгыз!

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03322-0

© Татарстан китап нəшрияты, 2017
© Рəхмəтулла С. И., 2017
© Хəбибуллин Р. Г., рəс., 2017

# Эчтәлек

Абыем ялга кайткан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Телевизор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Тел ачкычлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Энем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Көтү кайта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Дәү әнием сыйлый! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Балык тотканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Күлмәгемә төймә тактым! . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Ак икмәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Яңгыр алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Ял итә-итә-итә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Солдат фуражкасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Аңламыйлар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Беренче сыйныфка барам! . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Каникулда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Әнием өйдә юк чакта . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ауга — әти белән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Буранда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Песигә дә оя кирәк!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Бәрән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
«Йортта нинди терлекләр бар?..» . . . . . . . . . . . 18
Самолётта һәм поездда . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Әтәч һәм тавыклар турында . . . . . . . . . . . . . . 20
Карабодай боткасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Сыерыбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Утын көле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Тавыкмы? Йомыркамы?.. . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Чемодан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Туңдырмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Апамның ял көне... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Дәү әнием төшләр күргән... . . . . . . . . . . . . . . 30

Чөгендер үстерәм . . . . . . . . . . 32
Канатлы ат . . . . . . . . . . 33
Ай . . . . . . . . . . 33
Кемнәр?! . . . . . . . . . . 34
Умырзая . . . . . . . . . . 34
Бәбкә һәм каз . . . . . . . . . . 34
Күлдә . . . . . . . . . . 35
Дәү әни . . . . . . . . . . 35
Төсле каләмнәр . . . . . . . . . . 36
Каз бәбкәләре . . . . . . . . . . 36
Укырга өйрәнәбез . . . . . . . . . . 37
Бозау . . . . . . . . . . 37
Зур үстем! . . . . . . . . . . 38
Тауда . . . . . . . . . . 38
Ындыр табагында . . . . . . . . . . 39
Куян ник кыска койрыклы? . . . . . . . . . . 40
Әлифба . . . . . . . . . . 41
Самавырлар . . . . . . . . . . 42
Күзлек . . . . . . . . . . 42
Булыштым! . . . . . . . . . . 43
Космонавт . . . . . . . . . . 44
Капкачы . . . . . . . . . . 45
Табышмаклар . . . . . . . . . . 46
Шарадалар . . . . . . . . . . 56
    Тәүге хәреф . . . . . . . . . . 56
    Соңгы хәреф . . . . . . . . . . 59
    Бер иҗек кушсаң... . . . . . . . . . . 61
    «Исемнәр» темасына . . . . . . . . . . 64
Бишектән – ишеккә... . . . . . . . . . . 66
Сандыктагы хәзинә . . . . . . . . . . 71
Җаваплар . . . . . . . . . . 84

## Абыем ялга кайткан

Медале – «Батырлык өчен»,
Сержант погоны таккан –
Ил чигендә хезмәт иткән
Абыем ялга кайткан!

«Азга гына кайттым, – ди ул, –
Идәннәрне буярбыз.
Кышкылыкка утын кисеп,
Утын ярып куярбыз...»

Идән буядык,
утын да
Кышка җитәрлек булды:
Әтиемнең, әниемнең
Исе китәрлек булды.

Көтү көттек,
печән чаптык,
Күлдә каптырдык балык.
«Вәт егетләр ичмасам!» – дип
Таң калып тора халык.

Күрше әби коймасын да
Утырттык – авып яткан...
Ил чигендә хезмәт иткән
Абыем ялга кайткан!..





## Телевизор

Әти, әни көн дә иртән
Әйтә бер үк сүзләрен:
«Көн буе
телик карама,
Бозылмасын күзләрең!..»

Көндез күзләр бозыладыр,
Хактыр алар сүзләре –
Мин йоклап киткәч,
төн буе
Телик карый үзләре...



## Тел ачкычлары

...Әнием теләкләр теле:
«Тел ачкычлары бирсен!
Бүген мәктәпкә барасың,
Зур инде, улым, зур син!..»

...Әти, Коръән алып,
тәүләп
Мәчеткә бара, күр син!
Теләк теләп калдым аңа:
«Тел ачкычлары бирсен!..»

## Энем

Энем бик бәләкәй әле,
Әйталмый әйтер сүзен,
Сусагандыр –
чәй эчерәм,
Итәккә алып үзен.

Чәй кайнар – өреп суытам,
Аңа җылы да ярый.
«Кайнар түгелме?..» –
Чәйгә ул
Бармагын тыгып карый...



## Көтү кайта

Маллар таудан төште:
алар
Урамга сыймый хәтта.
Бәләкәй капканы ачам –
Сарыклар алдан кайта.

Зурысын да ачып куям,
«Ачма!» – дип беркем тыймый –
Сыерга...
зур капка кирәк,
Бәләкәенә сыймый!..



## Дәү әнием сыйлый!

...Дәү әни аш белән сыйлый:
«Ачыккансың ич, – ди ул. –
Икмәкләп аша,
тагын да
Салам бер чүмеч», – ди ул...

«Нәрсә ул – чүмеч?» –
дип сорыйм.
«Сөйләшми ашыйк! – диде. –
Кулыңда – кашыкмы?
Чүмеч...
Чүмеч – зур кашык!» – диде...

## Балык тотканда

Күлдә балык каптырабыз,
Күрәм:
абыем Кыям
Вакларын кире җибәрә...
Мин вакларын да җыям.

– Вакларын җибәр, –
ди абый,
Аптырап миңа карый...
– Алары – аквариумга,
Анда вагы да ярый!..

# Күлмәгемә төймә тактым!

Күлмәктән төймә
Өзелеп төшкән –
Көттем әнинең
Кайтуын эштән.

– Әни, так, – дидем, –
Күлмәккә төймә.
– Сал күлмәгеңне,
Ал, – диде, энә. –

Менә сиңа җеп,
Нык булсын төймәң,
Ләкин сак кылан
Энә-җеп белән!

Күзләдем энә –
Кыен эш түгел.
Төймә тагуы –
Уен эш түгел…



## Ак икмәк

Әтиемне сирәк күрәм:
«Эшнең кызу мәле, – ди, –
Басуларда көн-төн икмәк
Үстерәбез әле», – ди.

Тешләре генә ялтырый,
Елмая ике күзе.
Йөз ат көчле тракторны
Йөртә бит ул үзе!

«Әтиең үстергән!» – диеп,
Әни ак икмәк телә.
Кап-кара җирдә ак икмәк
Әти үстерә белә!

Бик сирәк күрешәбез шул:
«Эшнең кызу мәле, – ди, –
Ак икмәк үстерү серен
Өйрәтермен әле!» – ди.



## Яңгыр алдыннан

…Тавык канат асларына,
«Корт-корт!..» диеп,
Чебешләрен җыйды –
Яңгыр тияр дип…

…Казлар…
Казлар
күлгә китте,
Бәбкәләрен ияртеп…

## Ял итә-итә-итә...

Дәү әтием бара бүген
Зур апамны күрергә.
– Мин дә барам, – дидем, –
мине
Ал үзең белән бергә!

– Җәяү барам бит, арырсың:
Ерак бит күрше авыл...
– Җәяү булгач,
туктап-туктап
Ял итеп тә була ул...

Атлыйбыз:
яшел тугайлар,
Болыннар артта кала.
Дәү әтием, арыдым, дип,
Туктап-туктап хәл ала.

Менә чирәмдә тагын да
Дәү әтием ял итә.
Мин арымыйм:
физзарядка
Ясыйм бит мин һәр иртә!..





## Солдат фуражкасы

Әнием: «Мин аш пешерәм,
Син, улым Талип, – диде, –
Бозау кайтмаган,
бозауны
Алып кайт табып», – диде.

Тәрәзәдән тышка карыйм –
Күренмн хәтта урам.
Караңгы урамга
ялгыз
Чыгарга куркып торам...

Әтием, елмаеп кына:
«Кич тә булган, и-и-и, – диде, –
Башың өшер,
абыеңның
Фуражкасын ки!» – диде.

Абыем шәһәрдә хәзер...
Солдатта булган чакта,
Шушы фуражканы киеп
Торган ул чиктә сакта.



Сакта торган,
курыкмаган,
Чигенмәгән бер адым!..
...Йөгереп чыгып киттем дә
Күл буйларын урадым.

Тауга мендем...
Басып тордым
Хәтта зират каршында! –
Курыкмадым:
абыемның
Фуражкасы – башымда!

Ай калыкты,
йолдызлар да
Җемелдәп яна күктә...
...Кайтсам –
бозавыбыз мине
Капка төбендә көтә!

Мине хәзер төннәрен дә
Куркыталмый берни дә –
Абыемның фуражкасы
Эленеп тора чөйдә!



## Аңламыйлар...

Әнисе уята аны,
Дәү әнисе уята:
– Тор, то-о-ор! Чәй эч!..
Гата тормый:
Һаман да йоклап ята...



Кичә апалары белән
Җиләккә барып кайткан.
«Йокычы» дип уйламагыз,
Ул кичә арып кайткан...

– Тор, җиләкләп чәй эчәрбез!
Әллә... юри ятамы?!
Йокы җиләктән дә татлы! –
Аңламыйлар Гатаны...

## Беренче сыйныфка барам!

Көн дә мәктәпкә җыенам,
Әзер бөтен әйбер дә –
Беренче сыйныфка барам
Беренче сентябрьдә!

Укытучыма чәчәкләр
Сайлап алырмын әле,
Әниемне дә җитәкләп
Алып барырмын әле!

## Каникулда

Зур апам мәктәптә эшли –
Укыта ул мәктәптә.
Без каникулда булгач, ул
Ял да итә, әлбәттә.

Апам ял иткәндә, аңа
Ял итешәм әле мин:
Су ташышам, түтәлләргә
Су сибешәм әле мин.

Бакчада коңгыз җыябыз,
Тәрәзәләр юабыз.
Җиләккә барабыз, кайткач,
Тәмле каклар коябыз.

Ул – укытучы, аңлата,
Аңлыйм һәр сүзен дә мин.
Ул эшләгәнне эшләргә
Тырышам үзем дә мин.

Китапханәдән китаплар
Алабыз. «Кирәк, – ди ул, –
Китап укыган кешеләр
Булалар зирәк», – ди ул.

Мәктәпкә баргач, дусларга:
«Сагынып беттем, – диярмен. –
Каникулда апам белән
Мин ял иттем», – диярмен.



## Әнием өйдә юк чакта

Калага китте әнием,
Абыемны күрергә.
Әнием өйдә юк чакта
Нигә уйнап йөрергә?!

Гөлләргә су сибәсем бар,
Идәннәрне юасым.
Песигә сөт бирәсем бар,
Күлгә казлар куасым...

Дус кызларым уйнасыннар,
Йөгердем — көтә өем.
Газга чәй дә куясым бар —
Төшкә кайтыр әтием!..



## Ауга – әти белән...

Әти әйтә:
— Иртән ауга
Барам, куян атарга!..
Киемнәрен эзли энем...
— Кич бит... — дидем аңарга.

— Иртән кияр киемнәрне
Кич әзерләп куям, — ди. —
Әти белән
мин дә барам —
Аттырмыйм мин куян! — ди.

## Буранда

Күз ачкысыз буранда
Уйнап кердем урамда.

Көтеп кием кипкәнен,
Тышта буран беткәнен,

Әтием белән бергә
Көрәк ясыйбыз өйдә.

Күз ачкысыз буранда
Юл күмелгән урамда...

Буран тынсын, күрерсез –
Такыр юлдан йөрерсез!

